# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

30 октябрь 2023 ел   № 3

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Каенлык торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 26 октябрендә 15 сәгать 00 минутта уздырылган “Сез 2024 елда Каенлык авыл җирлеге территориясендә Каенлык торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

1.-Каенлык торак пунктында суүткәргеч торбаларны ремонтлап алыштыру;

- юлларны кышкы тоту: ягулык-майлау материаллары сатып алу, кар чистарту, тракторчының хезмәт хакы;

2. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2024 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарын һәм аларның гаилә әгъзаларын 1 кеше санында азат итәргә.

«РИЗА»   «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 266 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 137 кеше, бу 51,5 %ны тәшкил итә.

тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

“Риза” позициясе өчен гражданнар җыенында 137 катнашучы тавыш бирде; “Каршы” позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Каенлык торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

“Сез 2024 елда Каенлык авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә  үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

“а) Каенлык  торак пунктында суүткәргеч торбаларны ремонтлап алыштыру;

- юлларны кышкы тоту: ягулык-майлау материаллары сатып алу, кар чистарту, тракторчының хезмәт хакы”

- дигән мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип санарга.

2. 2024 елда мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын үзара салым түләүдән азат итәргә.

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Биектау муниципаль районы рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Каенлык авыл җирлеге башлыгы А.Ә.Әминов